КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 декабрь г.Казань № 1095

2025 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы турында

Психик бозылышлары булган инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационарны алыштыра торган технологияләрен үстерү, аларның тормыш сыйфатын яхшырту һәм аларны җәмгыятькә социаль интеграцияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
2025 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны 1 көн-урын өчен 1 240,92 сум күләмендә;
2025 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын 1 сәгатькә 65,31 сум күләмендә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында» 2023 ел, 5 декабрь, 1555 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин